# Мубаракшина Зәйнәпбикә Мубаракша кызы



Зәйнәпбикә Мубаракша кызы Мубаракшина 1927 нче елның 15 нче сентябрендә Югары Сон авылында колхозчы гаиләсендә беренче бала булып дөньяга килә. Сугыш башланган вакытта алар 5 бала булалар. Сугышның беренче көненнән үк Зәйнәпбикә апаның әтисен сугышка алып китәләр. ”Исән булсак бер кайтырбыз,”- дип киткән Мубаракша абый аяусыз сугышның беренче көннәреннән үк батырларча һәлак була. Шулай итеп, әниләре 5 бала белән тол кала. Сугыш башланганда Зәйнәпбикә апага нибары 12 яшь була. Ул 12 яшеннән үк колхозда төрле эшләрдә катнаша башлый.

Зәйнәпбикә апа, олы бала буларак, тормышның барлык авырлыгын үз җилкәсендә татый. Әниләре көне-төне колхоз эшендә: сарык фермасында сарыклар карый. Зәйнәпбикә апа башта укый, аннары әнисенә булышырга фермага бара. Ул бер көн дә калмыйча мәктәпкә йөрергә тырыша. 4 класс кына укырга туры килә аңа, чөнки тормышны алып бару өчен эшләргә кирәк була. Эшләмәгән бер эше дә калмый анының: яз көне 3-4 км ераклыктагы басудан фермага күтәреп салам ташыган, колхозның яшелчә бакчасында да, басуда ашлык уруда да, ындыр табагында ашлык чистартуда да эшләргә туры килә аңа.
14-15 яшеннән уракка йөргән, сабан сөргән, тырмалаган, трейдер белән ашлык тарткан, сыер, үгез җигеп эшләгән.

И Җир-Ана! Мондый мәхшәрне син
Күргән идеңмени моңарчы?!
Басуларны сыер,үгез җигеп,
Хатын-кызлар, картлар ермачлый.

- Сукага сыер җигәбез, сыеры булмаганнар үгез җигә. Атларны сугышка алып киттеләр, калганнары ачтан үлеп бетте. 1941 нче елны кызу булды, икмәк булмады. Ачка үлмәс өчен басудан черек бәрәңге эзләдек, кычыткан җыйдык, имән чикләвеген тарттырдык, солы кибәгеннән аш пешерә идек; урманнан яфрак җыеп, киптереп бәрәңге белән кушып пешереп ашый идек, - ди ул.

-Аякка кияргә чабата да бетте, - дип искә ала ул сугыш вакытын.

Сугыштан соңгы еллар да җиңелдән булмый шул. Кыш көне 18 яшьлек кызларны 8 км ераклыктагы урманга пычкы белән агач егарга, кисәргә җибәрәләр. “Аякта чабата, аяк туна иде” –дип сөйли Зәйнәпбикә апа.

Сугыш беткәннән соң 5 ел ачлык булды. Шул елларда көне буе эшләгәнгә 200 г он бирәләр иде. Кич эштән кайткач шул онны суга болгатып ашый торган идек,- дип авыр сулап куя Зәйнәпбикә апа. Тирә-юньдә ризыкланырлык үлән калмаганчы ашаган авыл халкы.

Тормыш иптәше белән тыныч тормышта яшәп 1 бала тәрбияләгәннәр алар. Гөлчирә апа балалар бакчасында эшләп лаеклы ялга чыга. Хәзерге көндә Зәйнәпбикә апа үзенең кызы Фирая апа тәрбиясендә яши.

Онытылмас 41 нче ел.
Мәхрүм итте безне әтидән,
Ә әниләр, ачлыктан саклап,
Алып калды безне үлемнән...